| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**Исполнительный комитет поселка городского типа Уруссу Ютазинского муниципального района** | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты** |
| 423950, п.г.т. Уруссу<br>ул. Пушкина, 38<br>тел. 2-86-53, 2-61-50<br>E-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru | 423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы<br>Пушкин урамы, 38<br>тел. 2-86-53, 2-61-50<br>E-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 16» март 2015 ел № 10

*Муниципаль хезмәткәрләр үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре,чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында*

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2014 елның 5 ноябрендәге 17 номерлы «шәһәр тибындагы Урыссу поселогы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук “шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» гы карарына ярашлы:

1. Гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр биләгән вакытта үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Кушымта бирелә торган исемлеккә кертелмәгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар да үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын
башкаручы Р.Ф. Вәдигуллин

карарына кушымта
Башкарма комитеты
Урыссу шәһәр тибындагы
Советының
2015 елның «16» мартыннан № 10

**Муниципаль хезмәткәрләр үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре,чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге**

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты җитәкчесе